***Мухаметзянов И. М. (РИИ, Казань)***
***Мухаметзянова И. Г. (КФУ, Казань)***

# МИЛЛИ МӘКТӘПЛӘРНЕҢ ЯЗМЫШЫ – БЕЗНЕҢ КУЛЛАРДА!

**Аннотация:** Урмышлы урта мәктәбе Татарстан республикасында гына түгел Башкортстан һәм Мордовия республикаларында да танылган мәктәпләрнең берсе. Бай тарихлы, мәдәният үзәге булып торган әлеге мәктәп Лениногорск районының үрнәк мәктәпләреннән санала. Мәгариф һәм фән министрлыгы республикадагы милли мәктәпләргә игътибарны аеруча арттырса иде. Милли мәктәпләргә төрле проектлар һәм эксперементаль мәйданчыклар булдыру авыл җирлеге өчен үзенә күрә отышлы адым. Татар теле һәм татар әдәбиятының киләчәге бүгенге көндә авыл җирлеге белән тыгыз бәйләнгән. Милли мәктәпләребезне сакласак, ана телебезне дә саклап калачакбыз.

**Төп сүзләр:** татар теле, татар әдәбияты, уку-укыту системасы, милли система, Сингапур системасы, электрон портал, интернет ресурслар.

**The fate of national schools is in our hands!**

**Annotation:** The secondary school of Urmushlu is one of the famous school in Tatarstan but outside of Bashkortstan and Mordovia. The school is considered exemplary in Lenonogorsk district. I would like Ministry education and science won't leave without attention such schools. Creation in the national schools of different projects and experimental sites is effective step. The future of the Tatar language and literature is closely connected with the village. If we save the national school, we will save native language.

**Key words:** The Tatar language, Tatar literature, system of education, a national system, the Singaporean system, electronic portal, Internet resources.

Милли мәгариф һәм милли мәктәп язмышы бүгенге көндә бик популярлашып китте. Телевидениядән дә радиодан да бихисап газета-журналларда милли мәктәпләрнең проблемалары хакында бик еш ишетергә туры килә. Күп кенә чыганакларга күз салсак, нигездә 70 – 80 укучыдан торган мәктәпләрне оптимизацияләү хакында инде күптәннән имеш-мимешләр йөри. Мәктәпләрне берләштерү бүгенге көн кадагы булып исәпләнә. Әлбәттә, әлеге юнәлешне хуплаучылар мәктәпләрне берәштерүдән ике куянны бер юлы ату белән аңлаталар: беренчедән укучыларның белем дәрәҗәсе күтәрелә, икенчедән балаларның күзаллаулары киңәя, өченчедән административ контроль көчәя, дүренчедән финанс мәсьләсе хәл ителә, ягъни мәктәпләрне берләштерүдән хезмәт хакын түләү бик күпкә азая.

Соңгы вакытта татар мәктәбе язмышы турында күп сөйләнде һәм сөйләнә. Бердәм дәүләт имтиханнарын татарча тапшыруны тыю, милли телләрне, тарихны, мәдәниятне укытуга чик куя торган 309 нчы законны кабул итү бик күпләрне борчуга салды. Күп кенә ата-аналар үзләренең балаларын рус мәктәпләренә бирә башлады, хәтта күп кенә татар мәктәпләрендә рус телендә укытуны өстен күрәләр. Бүгенге көндә милли мәктәпләрнең хәле ничек? Укыту эшчәнлеге ничек итеп оештырылган? Әлеге борчыган сорауларга җавап табуы кыен.

27 апрельдә Лениногорск районының Урмышлы урта мәктәбендә ачык чарада катнашырга туры килде безгә. Әлеге милли урта мәктәп Лениногорск шәһәреннән 60 километр ераклыкта урнашкан, ягъни район үзәгеннән иң ерак мәктәпләрнең берсе. Бинага килеп керү белән аның чисталыгына таң калдым. Чисталык һәм пөхтәлек милли мәктәпләргә хас үзенчәлек. Мәктәп директоры Хабибуллина Рузалия Наилевна актлар залында Урмышлы урта мәктәбенең эшчәнлеге белән таныштырды. Бигрәк тә ул мәктәпнең максатларына аеруча басым ясады:

– белем стандарты таләпләренә җавап бирерлек итеп белем бирү һәм «4»кә, «5»кә укучыларның санын арттыру;

– башлангыч сыйныфтан урта төркемгә күчкәндә белем сыйфатының түбәнәюенә юл

куймау;

– 9 нчы чыгарылыш сыйныф укучыларының имтиханнарын уңышлы тапшыруларына ирешү;

– укытучының профессиональ осталыгын күтәрү һәм яңарыш шартларында укучыларга югары сыйфатлы белем һәм тәрбия бирүдә информацион-коммуникатив технологияләрне нәтиҗәле куллану;

– методик эшне шәхси-юнәлешле итеп оештыру нәтиҗесендә педагогик кадрларның квалификациясен, профессиональ компетентлылыгын күтәрү;

– балаларның иҗади сәләтләрен үстерү, аларның сәламәтлекләрен ныгыту.

Әлеге максатлар белән таныштырып узганнан соң мәктәп эшчәнлегенең презентациясе тәкъдим ителде. Мәктәптә нибары 50 укучы гына белем алса да мәктәпнең нәтиҗәләренә таң калырлык. Бердәм дәүләт имтиханнары күрсәткеченә күз салсак, Лениногорск районында алдынгы мәктәпләрдән санала. Олимпиада юнәлешенә дә зур игътибар бирәләр. Быел гына Лениногорск районында уздырылган предмет олимпиадаларыннан җиде призлы урын алганнар, ә узган ел тугыз призлы урынга лаек булган әлеге мәктәп. Шулай ук ел саен диярлек республика күләмендә уздырыла торган предмет олимпиадаларында зур күрсәткечләргә ия булалар.

Мәктәп эшчәнлегендә татар теле һәм әдәбиятына зур игътибар бирәләр. Укучылырның һәм укытучылырның саф татарча сөйләшүләре безне бик тә сокландырды. Тел аша укытучылар милли мәктәптә зур эш алып баралар. Бигрәк тә Сәгадәт Имаметдиновна Мифтахова җитәклләгән «Шигъри каләм» түгәрәген республиканың барлык төбәкләрендә дә беләләр. Әлеге түгәрәккә мәктәпнең бар укучылары да йөри. Сәгадәт апа аларга әхлак тәрбиясе бирү белән бергә, балаларда илебезгә карата зур мәхәббәт тә уята. Үзенең түгәрәгендә балаларның язмаларына анализ ясый, рифмаларны дөрес һәм төгәл кую серләренә өйрәтә. Аның укучылырының хезмәтләре район һәм республика журналларында бихисап басылып чыга. Әле күптән түгел Казан шәһәрендә узган шигърият конкурсында призлы урын алып кайттылар. Семинарга килгән кунакларга укучылар тарафыннан шигъри түгәрәк эшчәнлегенең бер мизгеле күрсәтелде.

Мәктәпнең барлык сыйныфлары да заман таләпләренә туры китерелеп җиһазландырылган, кайбер сыйныфларда Сингапур структурасы нигезендә белем бирәләр. Урмышлы урта мәктәбе укытучылары Сингапур системасын үзләренең дәресләрендә бик

теләп кулланалар. Алга таба да әлеге система өстендә эшләүне күз алдында тоталар.

Укытучыларның барысы да ноутбук белән тәэмин ителгән, edu.tatar.ru дип аталаган электрон портал белән тыгыз элемтәдә торалар. Интернет ресурслардан актив файдаланалар, төрле җәмгыять төркемнәре белән даими эш алып баралар. Укытучылар үзләренә бирелгән ноутбук белән биш елдан артык эшлиләр, бүгенге көндә күп кенә ноутбуклар тузган хәлдә. Укытучыларга әлеге ноутбуклар белән эшләү читенлекләр китереп чыгара. Район идарәсе әлеге мәсьәләне чишүне тизләтсә яхшы булыр иде. Бу мәсьәлә шәһәр мәктәпләрендә инде күптән хәл ителгән.

Татар халкының күп кенә мәшһүр галимнәре, язучылары, укытучылары һәм башка өлкәдәге күренекле шәхесләре авыл мәктәпләрен тәмамлаганнар. Авыл баласы һәрдаим табигать белән бәйле. Авылның чиста һавасы, челтерәп аккан салкын чишмә сулары тәэсирендә ул чыныгып үсә. Бала яшь чагыннан эшкә өйрәнә. Милли авыл мәктәпләре хакында Казан педагогия көллиятенең өлкән укытучысы Мияссарова Илсөяр Хәбибулловна түбәндәге сүзләрне әйтте: «Мин авыл мәктәбен тәмамлаган укучыларны кыр чәчәкләре белән тиңлим. Әгәр кыр чәчәкләрен машина таптаса, яңгыр явып китү белән, алар башларын күтәрәләр. Авыл мәктәбен тәмамлап Казанга укырга килгән укучы да, кыр чәчәкләре яңадан калкып чыккан кебек, барлык авырлыкларга да каршы торырга сәләтле!»

Литература:

1. Конвенция ООН о правах ребенка. М., 1993.

2. Овчарова Р. В. Практическая психология в начальной школе. М., 1996 г.

3. Закон РФ «О социальной защите инвалидов в РФ» от 24.11.95 г.

4. Клюева Н. В., Касаткина Ю. В. Ярс., 1996 г. «Учим детей общению».

5. Коджаспирова Г. М., Коджаспиров А. Ю. Воспитание, Образование, Образование, Система образования // Словарь по педагогике. – М.: ИКРЦ «МарТ», 2005. – 448 с.

6. Статья С. И. Сабельниковой «Развитие инклюзивного образования».